**Яңа елда**

Якты өмет, якты хисләр
һәм янымда якыннарым
Бу яңа ел бүләк итәр
Хыялларның иң акларын.

Минем кулга кинәт кенә
Кар бөртеге килеп кунган
Оча-оча шатлыкларны
Һәрбер күңелгә тараткан

Кушымта:
Җем-җем итеп ап-ак карлар
Җирне каплый иң якты хыяллар
Җем-җем итеп ап-ак карлар
Һәрбер өйгә китерсен шатлыклар

Мин бүген иң бәхетле
Әти-әни кочагында
Җир шарының һәр өендә
Бәхетле булсын һәр бала.

Минем кулга кинәт кенә
Кар бөртеге килеп кунган
Һәрбер күңел эреп китә
Яңа елны яратудан.